**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЧЕРЕМШАНСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ НИЖНЕКАМЕНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**ТҮБӘН КӘМИНКӘ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕСОВЕТЫ**

**ул.Центральная, дом 51, с.Нижняя Каменка, 423114**

**Үзәк урам, 51 нче йорт, Түбән Кәминкә авылы, 423114**

**тел./факс email: 8-(84396) 2-35-21. Nkam.Cmn.2@tatar.ru**

№ 12 10 декабрь 2025 ел

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**Түбән Кәминкә авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

2026 елга җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә бюджет ассигнованиеләре бүлеп бирү турында Түбән Кәминкә авыл җирлеге башкарма комитеты мөрәҗәгатен карау хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 24.5 статьясына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 77 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 октябрендәге 288-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Башкарма комитетның 2025 елның 06 ноябрендәге № 81 карарын карап, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Түбән Кәминкә авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2026 елга Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Түбән Кәминкә авыл җирлеге бюджетына бюджет ассигнованиеләренең җитәрлек булмавын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Түбән Кәминкә авыл җирлеге башкарма комитеты мөрәҗәгатендә күрсәтелгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә аерым вәкаләтләрне финанслаудан кушымта нигезендә баш тартырга.

Түбән Кәминкә авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе Халиков Р.Р

Советның 2025 елның 10 декабрендәге
12 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Башкарма комитет өчен 2026 елда бюджет ассигнованиеләрен бүлеп бирү өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләр исемлеге**

| № п\п | Бюджет ассигнованиеләре белән ныгыту өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрнең аталышы | БАРЛЫГЫ мең сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | Гидротехник корылманы декларация алды тикшерүе | 600 000 |
| 2 | Эчә торган суның сыйфатын СанПин 2.1.4.1074-01 таләпләренә туры китерү | 4 700 000 |
| 3 | Су белән тәэмин итүгә лицензия алу өчен документлар әзерләү | 582 000 |
| 4 | Шәһәр төзелеше планын әзерләү | 420 000 |
| 5 | Янгын гидрантларын ремонтлау һәм алыштыру | 200 000 |
| 6 | Гидротехник корылмаларны карап тоту | 240 000 |
| 7 | Кышкы вакытта җирле әһәмияттәге юлларны норматив хәлдә тоту өчен махсус реагентлар сатып алу | 150 000 |
| 8 | Түбән Кәминкә һәм Кара Чишмә авыллары мәдәният йортларында янгынга каршы чаралар (түбәгә һәм сәхнә тартмасына сеңдерү) | 82 000 |
| 9 | Террорчылыктан саклануны Түбән Кәминкә һәм Кара Чишмә авыллары мәдәният йортларының куркынычсызлык паспортларына туры китерү ( тавыш белән ашыгыч хәбәр итүнең автоном системасын урнаштыру), янгын сүндергечләрне тутырып кую, Түбән Кәминкә һәм Кара Чишмә авыл мәдәният йортларында видеокүзәтү урнаштыру | 240 000 |
| | **БАРЛЫГЫ:** | 7 214 000 |